ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 11 12.03.2024 ел

*2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 6 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында*

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан торак йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 6 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез эшләнәсе эшләрне түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 6 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

«- Ак Чишмә торак пунктында һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга мемориаль такта кую (проектын төзү, проектны төзү буенча хезмәтләр күрсәтү, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, нигез салу, мемориал кую, килешү буенча эшләр өчен түләү)»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (peep//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы ______________ А.Г. Дәүләтгәрәев
(имза)